**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сарлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл жирлеге БАШЛЫГЫ**

ул. Центральная, д. 68А, село Сарлы
Азнакаевского муниципального района, 423315
Тел. 36-5-34

Үзәк урам, 68А, Сарлы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423315
Тел. 36-5-34

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь, 2020 ел №5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пунктында 2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, **карар итәм**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сөендек авылында 2021 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын ТР, Азнакай муниципаль районы, Сөендек авылы, Яшел ур., 34 адресы буенча урнашкан Сөендек авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 13 ноябрендә 14.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2021 елда Сарлы авыл җирлеге Сөендек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) янгын сүндерү автомобиле йөртүче хезмәтенә түләү, янгын сүндерү автомобиле өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу;

2) Сөендек авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) Сөендек авылы зиратларын карап тоту (перфоратор һәм генератор сатып алу);

4) Сөендек авылы Кооператив урамы буенча юлны ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү)?

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Сөендек авылы, Яшел урам, 34 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында,

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.Р.Шарипов